# КАРАР

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге составына керүче Иске Тәкмәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**06.12.2021** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 06 нчы декабрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлардан кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең Иске Тәкмәк авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2022елдаүзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

-Пирс төзү,пирска бара торган юлга вак таш җәю;
-Советская урамындагы кое тирәсен төзекләндерү;
-Урам яктырткычларын ремонтлау;
- Зәй елгасы аша уза торган күпергә 2 яктырткыч лампалар белән электр баганалары кую;
- Зиратнытөзекләндерү,койма тоту;
- Балалар мәйданчыгын төзекләндерү,
- Советская урамына пожар гидранты урнаштыру.».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 131 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 71 кеше кертелгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен 71 җыенда катнашучы тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең Иске Тәкмәк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.
2. « Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлардан кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең Иске Тәкмәк авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2022елдаүзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

-Пирс төзү,пирска бара торган юлга вак таш җәю;
-Советская урамындагы кое тирәсен төзекләндерү;
-Урам яктырткычларын ремонтлау;
- Зәй елгасы аша уза торган күпергә 2 яктырткыч лампалар белән электр баганалары кую;
- Зиратнытөзекләндерү,койма тоту;
- Балалар мәйданчыгын төзекләндерү,
- Советская урамына пожар гидранты урнаштыру.” - кабул ителгән.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Аксар авыл җирлеге башлыгы ____________ Ю.И.Гильманов